КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 14 март г.Казань № 248

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 26 апрель, 344 нче карары белән расланган «2019 – 2025 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның Татарстан Республикасына иркле күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 –2025 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның Татарстан Республикасына ирекле күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын, ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган һәм Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә үзгәреш кертү хакында» 2019 ел, 26 апрель, 344 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 2 сентябрь, 761 нче; 2020 ел, 28 гыйнвар, 30 нчы; 2021 ел, 22 апрель, 273 нче; 2022 ел, 26 гыйнвар, 59 нчы, 2023 ел, 18 гыйнвар, 20 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2019 –2025 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның Татарстан Республикасына ирекле күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына (алга таба – дәүләт программасы) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

дәүләт программасы паспортының «Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары

Дәүләт программасын финанслау күләме түбәндәгечә тәшкил итәчәк:

(мең сум)

| Ел | Дәүләт программасы бюджеты |
|---|---|
| 2019 | 1 510,0 |
| 2020 | 1 200,0 |
| 2021 | 900,0 |
| 2022 | 625,0 |
| 2023 | 900,0 |
| 2024 | 900,0 |
| 2025 | 3 791,2 |
| Барлыгы | 9 826,2 |

Шул исәптән дәүләт программасын гамәлгә ашыру өчен җаваплы вәкаләтле органга бүлеп бирелде:

(мең сум)

| Ел | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
|---|---|
| 2019 | 1 510,0 |
| 2020 | 1 200,0 |
| 2021 | 900,0 |
| 2022 | 625,0 |
| 2023 | 900,0 |
| 2024 | 900,0 |
| 2025 | 3 791,2 |
| Барлыгы | 9 826,2 |

Шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән:

(мең сум)

| Ел | Татарстан Республикасы бюджеты Татарстан |
|---|---|
| 2019 | 634,2 |
| 2020 | 504,0 |
| 2021 | 378,0 |
| 2022 | 250,0 |
| 2023 | 360,0 |
| 2024 | 360,0 |
| 2025 | 1 554,4 |
| Барлыгы | 4 040,6 |

Шулай ук Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелә торган килешү нигезендә күченеп килгән

<table>
<tr>
<td></td>
<td>ватандашларга өстәмә гарантияләр һәм социаль ярдәм чаралары күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр рәвешендә федераль бюджет акчасын түбәндәге күләмендә җәлеп итү күздә тотыла:<br><br>(мең сум)
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Федераль бюджет акчасы</th></tr>
<tr><td>2019</td><td>875,8</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>696,0</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>522,0</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>375,0</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>540,0</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>540,0</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>2 236,8</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>5 785,6</td></tr>
</table>
<br>Дәүләт программасын финанслау күләмнәренә ел саен төгәллек кертелергә мөмкин»;</td>
</tr>
</table>

дәүләт программасының IV бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IV. Дәүләт программасын гамәлгә ашыруга финанс ресурслары күләмнәре

Дәүләт программасының ресурслар белән тәэмин ителешенә түбәндәгеләр нигез була: Россия Федерациясе Президентының «Чит илдә яшәүче ватандашларның Россия Федерациясенә ирекле күчеп килүенә ярдәм күрсәтү чаралары турында» 2006 елның 22 июнендәге 637 номерлы Указы, «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2018 елның 21 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы, «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2019 елның 30 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы, «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2020 елның 27 ноябрендәге 78-ТРЗ номерлы, «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2021 елның 25 ноябрендәге 86-ТРЗ номерлы, «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2022 елның 23 ноябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары.

Дәүләт программасын финанслау күләме түбәндәгечә тәшкил итәчәк:

(мең сум)

| Ел | Дәүләт программасы бюджеты |
|---|---|
| 2019 | 1 510,0 |
| 2020 | 1 200,0 |
| 2021 | 900,0 |
| 2022 | 625,0 |
| 2023 | 900,0 |

| | |
|---|---|
| 2024 | 900,0 |
| 2025 | 3 791,2 |
| Барлыгы | 9 826,2 |

Шул исәптән дәүләт программасын гамәлгә ашыру өчен җаваплы вәкаләтле органга түбәндәгечә бүлеп бирелде:

(мең сум)

| Ел | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы Премьер-министры |
|---|---|
| 2019 | 1 510,0 |
| 2020 | 1 200,0 |
| 2021 | 900,0 |
| 2022 | 625,0 |
| 2023 | 900,0 |
| 2024 | 900,0 |
| 2025 | 3 791,2 |
| Барлыгы | 9 826,2 |

Шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән:

(мең сум)

| Ел | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |
|---|---|
| 2019 | 634,2 |
| 2020 | 504,0 |
| 2021 | 378,0 |
| 2022 | 250,0 |
| 2023 | 360,0 |
| 2024 | 360,0 |
| 2025 | 1 554,4 |
| Барлыгы | 4 040,6 |

Шулай ук Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелә торган килешү нигезендә күченеп килгән ватандашларга өстәмә гарантияләр һәм социаль ярдәм чаралары күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр рәвешендә федераль бюджет акчасын түбәндәге күләмендә җәлеп итү күздә тотыла:

(мең сум)

| Ел | Федераль бюджет акчасы |
|---|---|
| 2019 | 875,8 |
| 2020 | 696,0 |
| 2021 | 522,0 |

| | |
|---|---|
| 2022 | 375,0 |
| 2023 | 540,0 |
| 2024 | 540,0 |
| 2025 | 2 236,8 |
| Барлыгы | 5 785,6 |

1. Дәүләт программасының 4 нче кушымтасындагы 3.1 пунктында күрсәтелгән «Чит илдә яшәүче ватандашларга массакүләм мәгълүмат чаралары, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, «Ватандашлар» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы аша дәүләт программасын тормышка ашыру турында мәгълүмат җиткерү, истәлекләр, буклетлар бастырып чыгару, «кайнар линия» телефоннары эшен оештыру. Дәүләт программасына 4 нче кушымтаның 3.1 пунктында күрсәтелгән мәгълүматны актуаль хәлдә тоту 567,533 мең сум күләмендә планлаштырылган.

2. Дәүләт программасының 4 нче кушымтасындагы 3.2 пунктында күрсәтелгән «Россия Федерациясе дәүләт программасында катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын беренчел торак белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү (6 ай дәвамында торакның аренда кыйммәтенең бер өлешен компенсацияләү)» чараларын финанслау 7 026,762 мең сум күләмендә планлаштырылды.

3. Дәүләт программасының 4 нче кушымтасындагы 2.1 пунктында күрсәтелгән «Россия Федерациясе дәүләт программасында катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча һөнәри белем бирүнең төп программалары һәм өстәмә һөнәри программалар буенча укыту» чараларын финанслау дәүләт программасын гамәлгә ашыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан 562,57 мең сум күләмендә планлаштырылды.

4. Дәүләт программасының 4 нче кушымтасындагы 3.3 пунктында күрсәтелгән «Россия Федерациясе дәүләт программасында катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына медицина тикшерүен үткәрү һәм медицина ярдәме күрсәтү» чараларын финанслау 1 669,335 мең сум күләмендә планлаштырылды.

Дәүләт программасын финанслау күләмнәренә ел саен төгәллек кертелергә мөмкин.»;

дәүләт программасына 4 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

«2019 –2025 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның Татарстан Республикасына ирекле күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына
4 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының
2023 ел, 14 март, 248 карары редакциясендә)

## «2019 –2025 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның Татарстан Республикасына ирекле күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм чараларын финанслау

| Төп чаралар исеме | Башкару-чылар | Үтәү срогы | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү инди-каторлары, үлчәү берәмлеге | Индикаторлар күрсәткечләре | | | | | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанс бирү, мең сум | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | база ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
| 1 нче максат. Россия Федерациясе Президентының 2006 елның 22 июнендәге 637 номерлы Указы белән расланган Чит илдә яшәүче ватандашларыбызны Россия Федерациясенә ирекле күчеп килүенә ярдәм күрсәтү буенча дәүләт программасын (алга таба - Россия Федерациясе Дәүләт программасы) Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыруны тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 нче бурыч. Татарстан Республикасы икътисадының квалификацияле кадрларга ихтыяҗын тәэмин итүгә һәм аларның дефицитын киметүгә ярдәм итү, шул исәптән актуаль фәнни һәм технологик проблемалар белән шөгыльләнүче белгечләрне һәм галимнәрне җәлеп итү | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.1. »2019 – 2025 елларга чит илләрдә яшәүче ватан-дашларның Татарстан | ТР Эчке эшләр министрлы-гы, *ТР ХЭһСЯМ | 2019 – 2025 еллар | Татарстан Республика-сына килгән һәм Татар-стан Респуб-ликасы | 657 | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 | - | - | - | - | - | - | - |

*Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге – 6 нчы биттә.

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Республикасы-на ирекле күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасында (алга таба - дәүләт программасы) катнашучыларны һәм аларның Татарстан Республикасы территориясенә килгән гаилә әгъзалары Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгында исәпкә кую. | | | буенча Эчке эшләр министрлыгында исәпкә куелган Россия Федерациясе Дәүләт программасында катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары саны, кеше | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | миграция үсеше коэффициенты (10 мең кешегә) | 7,0 | ≥6,5 | ≥6,0 | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 2 нче бурыч. Россия Федерациясе Дәүләт программасында катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын эш белән тәэмин итүгә ярдәм, шул исәптән авыл җирлегендә эшкә урнашу юлы белән | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.1. Россия Федерациясе Дәүләт программасында катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин | ТР ХЭһСЯМ | 2019 – 2025 еллар | Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларында урта һөнәри, югары белем, өстәмә һөнәри белем алучы 25 яшькә кадәрге яшь категориясен | 2 | 14 | 14 | 14 | 14 | 14 | 14 | 14 | 87,0 РФБ<br>63,0 ТРБ | 15,3 РФБ<br>11,1 ТРБ | - | - | 37,2 РФБ<br>24,8 ТРБ | 37,2 РФБ<br>24,8 ТРБ | 154,68 РФБ<br>107,49 ТРБ |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча һөнәри укытуның төп программалары һәм өстәмә һөнәри программалар буенча укыту | | | дәге Россия Федерациясе Дәүләт программасында катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары саны | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3 нче бурыч. Россия Федерациясе Дәүләт программасында катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын ирекле күчерүгә ярдәм итә торган социаль-икътисадый һәм мәгълүмати шартлар оештыру, Россия Федерациясе Дәүләт программасында катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль хезмәтләр күрсәтү | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3.1. Чит илдә яшәүче ватандашларга дәүләт программасын массакүләм мәгълүмат чаралары, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, “Ватандашлар” автоматлаштырылган мәгълүмат системасы, истәлекләр, буклетлар бастыру, “кайнар линия” телефоннары эшен оештыру аша мәгълүмат бирү. Мәгълүматны актуаль халәттә тоту | ТР ХЭһСЯМ | 2019 – 2025 еллар | басмаларның тиражы, нөсхәләр | - | 3 000 | 6 845 | | | | | | 21,75 РФБ 15,75 ТРБ | 64,96 РФБ 47,04 ТРБ | | | | | |
| | | | вәкаләтле орган үткәргән ватандашларыбызның даими яшәү дәүләтләрендә Татарстан Республикасы дәүләт программасын тәкъдир итү саны, шул исәптән элемтәнең техник каналларын кулланып | 4 | 3 | 3 | - | - | - | - | - | 16,53 РФБ 11,97 ТРБ | - | - | - | - | - | - |
| | | | вәкаләтле орган уздырган Татарстан Республика- | | - | - | 3 | 3 | 2 | 2 | 2 | - | - | - | - | 36,72 РФБ 24,48 ТРБ | 36,72 РФБ 24,48 ТРБ | 157,608 РФБ 109,525 ТРБ |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | сы дәүләт программасын тәкъдир итү саны, шул исәптән элемтәнең техник каналларын кулланып | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3.2. Россия Федерациясе Дәүләт программасында катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын беренчел торак белән тәэмин итүгә ярдәм (6 ай дәвамында торакның аренда бәясенең бер өлешен компенсацияләү) | ТР Хезмәт министрлыгы, ТР ҖҮО (килешү буенча) | 2019 – 2025 еллар | 6 айдан да ким булмаган вакытка вакытлыча урнаштыру өчен торак урыннары бүлеп бирелгән йә күрсәтелгән срокка торак урынны наемга бирү белән компенсация ләнгән Россия Федерациясе дәүләт программасында катнашучылар саны, кеше | 19 | 40 | 40 | 40 | 40 | 40 | 40 | 40 | 665,67 РФБ 482,03 ТРБ | 528,7 РФБ 382,9 ТРБ | 434,2 РФБ 314,5 ТРБ | 277,68 РФБ 185,12 ТРБ | 364,68 РФБ 243,12 ТРБ | 364,68 РФБ 243,12 ТРБ | 1 498,812 РФБ 1 041,55 ТРБ |
| 3.3. Россия Федерациясе Дәүләт программасында катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына медицина тикшерүе һәм | ТР Хезмәт министрлыгы, ТР ССМ, ТР буенча ОФПСС | 2019 – 2025 еллар | адаптация чорында Татарстан Республикасында гарантияләнгән медицина хезмәте алган Россия | 657 | 150 | 150 | - | - | - | - | - | 84,85 РФБ 61,45 ТРБ | 87,0 РФБ 63,0 ТРБ | - | - | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| медицина ярдәме күрсәтү | | | Федерациясе Дәүләт программасында катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары саны, кеше | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы нигезендә түләү алмыйча күрсәтелә торган гарантияле күләмдә медицина ярдәме алган Россия Федерациясе Дәүләт программасында катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары саны, шул исәптән адаптация чорында Татарстан Республикасында ирекле медицина | | - | - | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 | - | - | 87,8 РФБ 63,5 ТРБ | 97,32 РФБ 64,88 ТРБ | 101,4 РФБ 67,6 ТРБ | 101,4 РФБ 67,6 ТРБ | 425,7 РФБ 295,835 ТРБ |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | иминияте шартнамәсе нигезендә, кеше | | | | | | | | | | | | | | | |
| Дәүләт программасы буенча барлыгы, шул исәптән: | | | | | | | | | | | | 1 510,0 | 1 200,0 | 900,0 | 625,0 | 900,0 | 900,0 | 3 791,2 |
| Россия Федерациясе бюджеты | | | | | | | | | | | | 875,8 | 696,0 | 522,0 | 375,0 | 540,0 | 540,0 | 2 236,8 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | | | | | | | | | | | | 634,2 | 504,0 | 378,0 | 250,0 | 360,0 | 360,0 | 1 554,4 |

Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:

ТРБ – Татарстан Республикасы бюджеты;
РФБ – Россия Федерациясе бюджеты;
ТР буенча ЭЭМ – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы;
ТР ССМ – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы;
ТР ХЭhСЯМ – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү hәм социаль яклау министрлыгы;
ТР ҖҮО - Татарстан Республикасы шәһәр округларының hәм муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары;
ТР буенча РИФ - Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе Пенсия hәм социаль иминиятләштерү фондының Татарстан Республикасы буенча территориаль органы.